**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 ноябрь, 2023 ел.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2023 елның 29 ноябрендә 12 сәгатьтә, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2023 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- җирлек торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;
« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 15 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 14, бу 93,3 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 14 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- җирлек торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М. Емельянова